КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 15 декабрь г.Казань № 1144

«Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 ел, 21 апрель, ТРЗ-24 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру буенча чаралар турында

«Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 ел, 21 апрель, ТРЗ-24 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә, шулай ук уңай инвестицион климат һәм Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларны, сәнәгать кластерларын үстерү өчен шартлар булдыру максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) парклары, сәнәгать технопарклары һәм сәнәгать кластерларына, сәнәгать технопаркларының идарә компанияләре һәм сәнәгать технопаркы составында булган технологик инфраструктура һәм сәнәгать инфраструктурасы объектларыннан файдаланучы сәнәгать өлкәсендә эшчәнлек субъектларына мөнәсәбәттә сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне стимуллаштыру чаралары куллану тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгын «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән аерым стимуллаштыру чаралары кулланылган сәнәгать эшчәнлеге субъектлары реестрын алып бару буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 6 декабрь, 692 нче; 2008 ел, 28 гыйнвар, 36 нчы; 2008 ел, 22 февраль, 99 нчы; 2008 ел, 29 май, 341 нче; 2009 ел, 13 февраль, 84 нче; 2009 ел, 8 июнь, 377 нче; 2009 ел, 12 октябрь, 714 нче; 2010 ел, 15 июнь, 469 нчы; 2010 ел, 18 ноябрь, 908 нче; 2010 ел, 1 декабрь, 966 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 12 апрель, 287 нче; 2011 ел, 6 июнь, 457 нче; 2011 ел, 1 сентябрь, 731 нче; 2011 ел, 12 сентябрь, 759 нчы; 2011 ел, 2 декабрь, 984 нче; 2012 ел, 18 гыйнвар, 24 нче; 2012 ел, 30 май, 443 нче; 2012 ел, 25

июль, 630 нчы; 2012 ел, 6 ноябрь, 967 нче; 2013 ел, 11 февраль, 87 нче; 2013 ел, 7 март, 154 нче; 2013 ел, 23 ноябрь, 914 нче; 2014 ел, 16 май, 326 нчы; 2014 ел, 11 август, 580 нче; 2015 ел, 28 май, 386 нчы; 2016 ел, 26 февраль, 120 нче; 2016 ел, 19 сентябрь, 656 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 361 нче; 2017 ел, 11 декабрь, 972 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1114 нче; 2018 ел, 27 сентябрь, 865 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1.96 пунктта «индустриаль (сәнәгать) паркларын» сүзләреннә соң «, сәнәгать технопаркларын» сүзләрен өстәргә;

4.1.98 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.98. Аларга карата Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән сәнәгать өлкәсендәге стимуллаштыру чараларын куллану максатларында, индустриаль (сәнәгать) парклары, сәнәгать технопарклары, сәнәгать кластерлары, индустриаль (сәнәгать) паркларының, сәнәгать технопаркларының идарә компанияләре, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмаларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән өстәмә таләпләргә туры килүен раслый.»;

4.1.105 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.105. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән таләпләргә туры килүне раслаган сәнәгать кластерлары, сәнәгать технопарклары, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмалары, сәнәгать технопаркларының идарә компанияләре, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгын «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә аерым стимуллаштыру чаралары кулланылган сәнәгать өлкәсендә эшчәнлек субъектлары реестрын алып баруны гамәлгә ашыра, шулай ук әлеге реестрларны алып бару тәртибен билгели.».

4. «Татарстан Республикасы Инвестицион-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасына Татарстан Республикасы сәнәгатен үстерү дәүләт фондлары өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан керә торган акча исәбеннән Татарстан Республикасы сәнәгате өлкәсендә эшчәнлек субъектларына финанс ярдәмен гамәлгә ашыруның максатчан нәтиҗәлек күрсәткечләрен эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә тәкъдим итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин